ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«20» мая 2021 ел № 142

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы территориясендә укудан буш вакытта 14 яшьтән 18 яшькә кадәрге балигъ булмаган гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру турында

«Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» 1991 елның 19 апрелендәге 1032-1 номерлы Россия Федерациясе Законы, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 30 ноябрендәге 880 номерлы «Татарстан Республикасында урта һөнәри белеме булган һәм беренче тапкыр эш эзләүче эшсез гражданнарны укудан азат вакытта 14 яшьтән 18 яшькәчә балигъ булмаган гражданнарны, эш эзләүдә кыенлыклар кичерүче эшсез гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» боерыгы, «2014-2025 елларга Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итүгә ярдәм» дәүләт программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 09.08.2013 № 553 карары нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Расларга:

2021 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы территориясендә уздырыла торган теркәлгән 200 балигъ булмаган гражданны эшкә урнаштыруга җәлеп итеп, вакытлыча эшләрнең төп төрләре исемлеге (1 нче кушымта);

Әгерҗе муниципаль районы учреждениеләре, оешмалары, предприятиеләре эшчәнлеге барышында «Менделеевск районы халкын эш белән тәэмин итү үзәге» филиалы белән берлектә 2021 елда Әгерҗе районы буенча «Менделеевск районы халкын эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ филиалы белән берлектә булдырыла торган эш урыннары санын исәпләп, балигъ булмаган гражданнарны каникул һәм укудан азат итү өчен вакытлыча эш урыннары исемлеге (2 нче кушымта).

2. «Менделеевск районы ЦЗН» ДКУ Әгерҗе районы филиалы белән берлектә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы территориясендә оештырыла торган вакытлы эшләр күләмнәрен, билгеле бер территориянең социаль инфраструктурасын үстерү зарурлыгыннан чыгып, билгесез халык санын

һәм составын исәпкә алып, аерым территориянең социаль инфраструктурасын үстерү зарурлыгыннан чыгып билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең кураторлык юнәлешләре буенча урынбасарларына буш торучы халыкка вакытлы эшләрне оештыру тәртибе һәм бу эшләрдә катнашу шартлары турында мәгълүмат бирү эшен оештырырга.

4. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ җитәкчесенә, учреждение, оешма, предприятиеләр директорларына (милек рәвешләренә бәйсез рәвештә) Әгерҗе районы буенча «Менделеевск районы ЦЗН» ДКУ Филиалына вакытлы эшләр башкаруны оештыруда ярдәм күрсәтергә тәкъдим итәргә.

5. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

6. Карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О.А. Баженовага йөкләргә.

**Җитәкчесе** **А.Э. Акбашев**

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Башкарма комитетының
20.05.2021 №142
карарына 1 нче кушымта

**2021 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы территориясендә уздырыла торган теркәлгән 200 балигъ булмаган гражданны эшкә урнаштыруга җәлеп итеп, вакытлыча эшләрнең төп төрләре исемлеге**

1. Авыл хуҗалыгы эшләре: авыл хужалыгы культураларын карау һәм урып-җыю, Әгерҗе муниципаль районы территорияләрен җыештыру.

2. Участокларда җитештерү һәм хезмәт урыннарын җыештыру (зарарлы хезмәт шартларыннан тыш).

3. Шәһәр урманнарын көнкүреш чүп-чарыннан, ауган агачлардан (коры-сары киселмичә) җыештыру.

4. Шәһәр һәм район территорияләрен төзекләндерү һәм яшелләндерү.

5. Мәгариф учреждениеләре территорияләрен, спорт мәйданчыкларын, ял итү урыннарын (чәчәкләр, куаклар утырту, су сибү, утау) төзекләндерү.

6. Куаклыкларны кисү (биеклеккә күтәрелмичә).

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Башкарма комитетының
20.05.021 № 142
карарына 2 нче кушымта

**Әгерҗе муниципаль районы учреждениеләре, оешмалары, предприятиеләре эшчәнлеге барышында «Менделеевск районы халкын эш белән тәэмин итү үзәге» филиалы белән берлектә 2021 елда Әгерҗе районы буенча «Менделеевск районы халкын эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ филиалы белән берлектә булдырыла торган эш урыннары санын исәпләп, балигъ булмаган гражданнарны каникул һәм укудан азат итү өчен вакытлыча эш урыннары исемлеге**

| Учреждениеләр, оешмалар, предприятиеләр исемнәре | Барлыкка килә торган эш урыннары саны |
|---|---|
| МУП «Төзелеш идарәсе» | 1 |
| ҖЧҖ «Нәврүз» | 2 |
| ҖЧҖ «Агрофирма-Әгерҗе» | 1 |
| «Татарстан Республикасы Әгерҗе шәһәренең 2 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | 40 |
| *Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының 4 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе* | 18 |
| *Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Әгерҗе шәһәренең 1 нче гимназиясе муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе (Мәктәп - электрон белем бирү компетенциясе үзәге)* | 31 |
| *Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Бима урта гомуми белем бирү мәктәбе муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе* | 14 |
| *Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Салагыш урта гомуми белем бирү мәктәбе муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе* | 2 |
| *Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Красный Бор урта гомуми белем бирү мәктәбе муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе* | 15 |
| *Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Сарсак-Омга лицее муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе* | 12 |
| Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Тирсә урта гомуми белем бирү мәктәбе муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | 20 |
| Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Көчек урта гомуми белем бирү мәктәбе муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | 2 |

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Т.Гыйззәт исемендәге 3 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | 41 |
| «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ | 1 |
| **БАРЛЫГЫ** | **200** |